МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ
ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ
И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ
ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ
ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

06.05.2019 № 180

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының 2017 ел 21 нче июль № 437 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә шәхси башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керергә рөхсәт бирү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

2004 ел 27 нче июль № 79-ФЗ «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның 17 нче статьясындагы 1 нче өлешенең 3 нче пункты нигезендә б о е р ы к б и р ә м :

1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының 2017 ел 21 нче июль № 437 «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә шәхси башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә итү органнары (алда – Тәртип) составына керергә рөхсәт итү тәртибе турында» боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә шәхси башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә итү

органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибенә алдагы үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 1 пунктындагы икенче абзацында «бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы» сүзләрен алырга;

1.2. Тәтипнең 1 нче кушымтасын яңа теркәлгән редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге боерыкны министр урынбасарларына, министрлыкның структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм дәүләт граждан хезмәткәрләренә җиткерергә.

3. Биредәге Боерыкны үтәү контролен үземә калдырам.

Министр вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы О.А. Степущенко

Татарстан Республикасы ГТХМда
Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен эшкә алучы вәкиленең коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керергә рөхсәт бирүе тәртибенә
№ 1 кушымта

(Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының 06.05.2019 № 180 боерыгы редакциясендә)

Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрына

______________________________
(Ф.И.А., урынбасар вазифасы һәм структура
______________________________
бүлеге, яшәү урыны адресы
______________________________
(телефон номеры)

Татарстан Республикасы ГТХМда Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен эшкә алучы вәкиленең коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керергә рөхсәт бирүе турында
гариза

Идарә итүдә катнашырга, коллегиаль идарә органы составына керергә рөхсәт итүне сорыйм (кирәгенең астына сызарга)

______________________________________________________________
(иҗтимагый оешма,
______________________________________________________________
торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы,
______________________________________________________________
күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәте исеме)

бушлай нигездә ______________________________________________
______________________________________________ сыйфатында
(бердәм башкарма орган яки коллегиаль идарә органы исеме)

______________ ______________ ______________
(дата) (имза) (фамилия, инициаллар)